**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Тойкинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Джалиля , д. 19, село Тойкино,
Азнакаевского муниципального района, 423302
Тел. (факс) 45-0-89

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге башкарма комитеты**

Җәлил урамы,19, Туйкә авылы
Азнакай муниципаль районы, 423302
Тел. (факс) 45-0-89

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 август 2017 ел. № 12

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлегенең озак сроклы чорга бюджет фаразын әзерләү һәм раслау тәртибен, гамәлдә булу чорын, составына һәм эчтәлегенә таләпләрне раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге Уставы нигезендә

Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге
Башкарма комитеты карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлегенең озак сроклы чорга бюджет фаразын әзерләү һәм раслау тәртибен, гамәлдә булу чорын, составына һәм эчтәлегенә таләпләрне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык Закирова Р.Р